**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Чубар-Абдул авыл җирлеге карары**

Чубар-Абдул авылы № 182 «22» июнь 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районының Чубар-Абдул авыл җирлеге Советына
дүртенче чакырылыш депутатлар сайлау турында

2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 10 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 23 статьясы, 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының " Чубар-Абдул авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 13 статьясы нигезендә,

Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чубар-Абдул авыл җирлеге Советына дүртенче чакырылыш депутатлар сайлауларын 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә.

2. Әлеге карарны, аны кабул иткәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча, район «Маяк» газетасында бастырырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakvevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Н.Ә.Фәтхетдинов